| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
| ЮЛБАТСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮЛБАТ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| 422077, Республика Татарстан, с. Юлбат, ул. Г.Тукая, 57 тел. (84362) 43-7-22 | 422077, Татарстан Республикасы, Юлбат авылы, Г.Тукай урамы, 57 йорт тел. (84362) 43-7-22 |

e-mail: Ulbat.Sab@tatar.ru

| | |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ 29.06.2020 | КАРАР № 24 |

Юлбат авыл башкарма комитетының 2016 елның 4 маендагы 20 нче номерлы «Муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында" карарына үзгәрешләр кертү турында»

Район прокуратурасының 2020 елның 19 июнендәге 02-08-02-72-2020 номерлы протесты һәм "Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында" 2019 елның 2 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль Законы нигезендә Саба муниципаль районы Юлбат авыл башкарма комитеты

КАРАР КЫЛДЫ:

Юлбат авыл башкарма комитетының 2016 елның 4 маендагы 20 нче номерлы «Муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган муниципаль торак контролен тормышка ашырганда тикшерүләр үткәрү буенча административ регламентка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.1 пунктын киләсе эчтәлектәге 3.1.1 пунктчасы белән тулыландырырга:

«3.1.1. Планлы тикшерүнең еллык планына планлы тикшерүләрне кертү өчен нигез булып кабул иткән көннән бер ел үткәннән соң кертелә:

- дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган уведомлениегә туры китереп, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау;
- социаль файдаланудагы беренче наемга алынган торак йортның муниципаль реестрында, торак урыннарны наймлаучы булып торучы, эшчәнлеге тикшерелергә тиешле зат булган Социаль файдаланудагы наемга алынган йортларның муниципаль реестрында исәпкә кую;
- юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата соңгы планлы тикшерүне үткәрү тәмамлануы;
- коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларын билгеләү һәм үзгәртү.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: Т.Р. Шәмсиев